**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ МАМАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘМӘШИР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Мәмәшир авылы

«31» октябрь, 2023 ел № 35

Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 10 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Мәмәшир авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 10 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (2018 елның 31 октябрендәге 29 номерлы, 2019 елның 15 маендагы 8 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 10 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 7 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 17 номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 7 номерлы,2023 елның 31 октябрендәге 30 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә классы чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Мәмәшир авыл җирлеге башлыгына классы чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702